КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 14 апрель

г.Казань

№ 229

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 19 май, 388 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1040 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 март, 195 нче; 2012 ел, 10 октябрь, 844 нче; 2013 ел, 19 март, 193 нче; 2013 ел, 18 июль, 501 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 859 нчы; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 22 октябрь, 773 нче; 2015 ел, 11 июнь, 426 нчы; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1072 нче; 2018 ел, 8 август, 643 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 952 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2019 ел, 29 апрель, 359 нчы; 2019 ел, 6 сентябрь, 797 нче; 2019 ел, 25 октябрь, 957 нче; 2020 ел, 31 гыйнвар, 62 нче; 2020 ел, 11 февраль, 98 нче; 2020 ел, 12 май, 381 нче; 2020 ел, 3 июнь, 464 нче; 2020 ел, 3 сентябрь, 781 нче; 2021 ел, 26 гыйнвар, 25 нче; 2021 ел, 20 июль, 608 нче; 2021 ел, 12 октябрь, 970 нче; 2022 ел, 19 май, 474 нче; 2022 ел, 3 август, 753 нче; 2023 ел, 3 февраль, 91 нче; 2023 ел, 22 март, 320 нче; 2023 ел, 24 июнь, 750 нче; 2024 ел, 15 июль, 557 нче; 2024 ел, 28 август, 705 нче; 2025 ел, 22 гыйнвар, 31 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы буенча.»;

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«кызыксынучы республика башкарма хакимият органнары белән берлектә, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәгариф оешмаларында белем алучылар арасыннан чит ил гражданнарын (мигрантларны) һәм гражданлыгы булмаган затларны социаль һәм мәдәни адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән чараларны эшләүне һәм гамәлгә ашыруны башкара.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин